ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
«$1^1$) урманнарны урман паркы зоналарында урнашкан урманнарга, яшел зоналарда урнашкан урманнарга кертү турында карарлар кабул итү;»;
б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) урманнар урнашкан урман паркы зоналарында функциональ зоналарны билгеләү, Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән урманнар урнашкан җирләрнең мәйданын һәм чикләрен билгеләү һәм үзгәртү;»;
в) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:
«$7^1$) урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләренә карата гавами сервитутлар урнаштыру;»;

2) 5 статьяда:
а) 2 өлешнең 2 пунктында «(урман паркы)» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 5 өлешнең 2 пунктында «(урман паркында)» сүзләрен төшереп калдырырга;
в) 7 өлештә «(урман парклары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 7 статьяның 1 өлешендәге бишенче абзацта «вакытлыча корылмалар» сүзләрен «капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 14 декабрь
№ 101-ТРЗ